**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «24» октябреннән № 429

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2016 елның 27 июлендәге 293 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 ст. 2 өлеше нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2016 елның 27 июлендәге 293 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- кушымтаның 40 пунктында 1 һәм 2 пунктчаларында

«1) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә зыян китерү куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килү;

2) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә зыян китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү» сүзләрен

«1) гражданнар тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль документларына, Россия Федерациясе архив фонды документларына, Милли китапханә фонды составына керә торган аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычына ия булган документларга;

2) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), музей предметларына һәм музей коллекцияләренә, аеруча кыйммәтле, шул исәптән уникаль, Россия Федерациясе архив фонды документларына, Милли китапханә фонды составына керүче аеруча тарихи, фәнни, мәдәни әһәмияткә ия булган документларга, дәүләт иминлегенә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүгә, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерү;

3) кулланучыларның хокукларын бозу (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта).» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**